ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә «һәм Татарстан Республикасында музей әйберләре һәм музей тупланмалары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 1, 3 һәм 6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

3) 6 статьяның 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 4 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

5) 15 статьяда:
а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«15 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт музейларын оештыру һәм аларның эшчәнлеге шартлары**»;
б) 1 өлештә «Татарстан Республикасында музейлар» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт музейлары» сүзләренә алмаштырырга;

6) 23 статьяның 4 өлешендә беренче җөмләне төшереп калдырырга;

7) 24 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 27 декабрь
№ 100-ТРЗ